ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.02.2019 с.Старое Дрожжаное №11

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законга ( алга таба - 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 1 декабрендәге 48 номерлы карары белән расланган (2019 елның 6 февралендәге 5 номерлы редакциядә) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү Тәртибенең **10.4 пунктына** үзгәреш кертәргә, "хокук куллану функцияләрен, миграция сферасында контрольлек итү, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәте күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органының территориаль органы" дигән сүзләрне "эчке эшләр сферасындагы федераль башкарма хакимият органының территориаль органы" дигән сүзләргә алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге үзгәрешләргә таянып эшләргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм гehttp://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Чүпрәле муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Э.С.Әхмәтовка йөкләргә.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы М.Р. Гафаров